ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.11.2017 Казан ш. № 10-31/кс

2018 елга эчә торган суга, су бүлүгә һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчә торган суга, су бүлүгә һәм агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифларны билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Шушы карар кушымтасында күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмаларга ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 10.11.2017
№ 10-31/кс карарына кушымта

## 2018 ел өчен салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчә торган суга, су бүлүгә һәм агынты суларны транспортлауга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | | Су бүлүгә тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | | Агынты суларны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр |
| | Арча муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Водоканал-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 36,62 | 38,07 | 33,52 | 33,52 | | |
| | Биектау муниципаль районы | | | | | | |
| 2 | «Бөреле коммуналь челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 21,68 | 22,50 | 36,53 | 38,09 | | |
| | Лаеш муниципаль районы | | | | | | |
| 3 | «XXI гасыр җитештерү-төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | |
| 3.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)** | 53,31 | 55,47 | 67,40 | 70,13 | | |
| 3.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 45,18 | 47,01 | 57,12 | 59,43 | | |

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | | Су бүлүгә тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | | Агынты суларны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр |
| | Мамадыш муниципаль районы | | | | | | |
| 4 | «Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 22,97 | 23,78 | | | | |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | | | |
| 5 | “Идел-Чулман фәнни-тикшеренү һәм конструкторлык-технологик су урман транспорты институтының тәҗрибә-җитештерү заводы” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | | | | | 27,90 | 29,05 |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | | | |
| 6 | «Бриг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 35,34 | 36,68 | 17,99 | 18,65 | | |
| 7 | «Шереметьевский ЖилСтройСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 31,32 | 31,99 | 44,66 | 44,72 | | |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.
<**> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге